СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**29.12.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 52**

Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләгән чорда пенсия яшенә җиткән яисә эшкә яраклылыгын югалткан һәм үз вәкаләтләрен туктаткан (шул исәптән вакытыннан алда) муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләгән чорда пенсия яшенә җиткән яисә эшкә яраклылыгын югалткан һәм үз вәкаләтләрен туктаткан (шул исәптән вакытыннан алда) муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне, әлеге карарга кушымтада каралганча, расларга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 28 октябрендәге 19 номерлы;
- «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның пенсиягә чыгуына бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 16 августындагы 117 номерлы.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырырга (халыкка җиткерергә).

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П.Афанасьев**

**Зеленодольск муниципаль районы Советының 2025 елның 29 декабрендәге 52 номерлы карарына кушымта**

**Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаны биләгән чорда пенсия яшенә җиткән яисә эшкә яраклылыгын югалткан һәм үз вәкаләтләрен туктаткан (шул исәптән вакытыннан алда) муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затлар «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм: 1) муниципаль вазыйфаны кимендә биш ел даими нигездә йә җирле үзидарә органының тулы бер вәкаләтләр срогында, әмма өч елдан да кимрәк булмаган срокта биләсә;

2) муниципаль вазыйфаны башкару чорында пенсия яшенә җиткән яки эшкә яраклылыгын югалткан вәкаләтләрнең туктатылуы (шулай ук вакытыннан алда) белән бәйле рәвештә вазыйфадан азат ителсә картлык (инвалидлык)буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә түләү хокукы булганда, вәкаләтләре туктатылган көнгә биләгән вазыйфа буенча билгеләнгән ун тапкыр айлык акчалата түләү күләмендә әлеге Нигезләмә нигезендә бер тапкыр акчалата түләүгә хокуклы.

2. Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәүгә, бурычларны башкармауга бәйле рәвештә йә «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 1 өлешенең 1 - 3 пунктларында, 1 өлешнең 6, 7 һәм 10 пунктлары белән һәм 30 статьясындагы 2 өлешендә каралган нигезләр буенча муниципаль вазыйфаларны биләгән һәм вәкаләтләре туктатылган затларга әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән гарантияләр каралмаган.

3. Муниципаль вазыйфаны биләүче һәм муниципаль вазыйфаны башкару чорында пенсия яшенә җиткән яки эшкә яраклылыгын югалткан затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар Зеленодольск муниципаль районы Советы тарафыннан кабул ителә (алга таба -  бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар) һәм бер үк вакытта Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органы (алга таба - җирле үзидарә органы) муниципаль вазыйфа биләүче затның вәкаләтләрен туктату(шул исәптән вакытыннан алда) турында карар кабул итү белән бергә рәсмиләштерелә.

4.  Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү  муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләре туктатылганчы ук турыдан-туры вәкаләтләрен гамәлгә ашырган Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органы (алга таба - җирле үзидарә органы) тарафыннан түләнә.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән шартларга туры килә торган бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү турында Зеленодольск

муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затның гаризасы кергән көннән алып 3 (өч) календарь көн эчендә «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә (алга таба - финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документлар тапшыра:

5.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаны биләүче затның айлык акчалата түләнүе турында белешмә;

5.2. бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар;

5.3. җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган дәүләт һәм (яисә) муниципаль вазыйфада һәм дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәттә эшләү стажы турында белешмә;

5.4. җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билет күчермәләре;

5.5. бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү исәбе;

5.6. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затның эш стажын раслаучы башка документлар (булган очракта)

6. Финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органы тарафыннан документлар тапшырылган көннән алып 10 (ун) календарь көн эчендә әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджетына үзгәрешләр кертү турында карар проектын Район советына җибәрә һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өчен бюджет ассигнованиеләре турында һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында җирле үзидарә органына хәбәрнамә җиткерә.

7. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән хәбәрнамәләр нигезендә 10 (ун) календарь көн эчендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыра.

8. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бер мәртәбә башкарыла.

Дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата түләү яисә дәүләт (муниципаль) вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү инде бирелгән затларга бер тапкыр акчалата түләү гамәлгә ашырылмый.